РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«31» март 2022 ел г. Альметьевск № 526

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Балалар һәм яшьләр эшләре идарәсе ведомство буйсынуындагы яшьләр сәясәтенең муниципаль бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 31 августындагы 1295 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы яшьләр сәясәтенең дәүләт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 14 августындагы 665 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыкка буйсынучы яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары һәм аерым басма оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 09 февралендәге 102 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Балалар һәм яшьләр эшләре идарәсе ведомство буйсынуындагы яшьләр сәясәтенең муниципаль бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 31 августындагы 1295 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 04 июлендәге 1215 номерлы, 2020 елның 21 апрелендәге 535 номерлы, 2022 елның 28 гыйнварындагы 100 номерлы, 2022 елның 21 мартындагы 428 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

«Яшьләр сәясәте учреждениеләрендә хезмәткәрләрнең төп окладларын билгеләү» 2 бүлегенең 2.2 пунктында:

22 064

Зак. № 305-2000

таблицадан соң икенче абзацта «11 687» саннарын «14 487» саннарына алмаштырырга;

таблицадан соң өченче абзацта «14 220» санын «16 720» саннарына алмаштырырга.

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе — А.М. Каюмов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ